Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында гражданнар җыены

КАРАР

21 ноябрь 2025 ел № 5

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 10 ноябрендәге 3 нче номерлы карары нигезендә, гражданнар җыенының 2025 елның 21 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә: сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 118 катнашучы кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә  катнашучылар саны 68 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «хуплый» позициясе өчен гражданнар җыенында 68 катнашучы тавыш бирде, «каршы» позициясе өчен 0 тавыш. Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә,  I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан Сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән 50%ка киметеп 500 сум күләмендә,  ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат  итеп, кертергә  һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( Сәйтәк авылындагы юлларны кардан чистарту вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, Сәйтәк авылында юлларны тигезләү,).
- Су белән тәэмин итү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (суга батыру насослары сатып алу).
- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу)

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru  һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru  “Бәзәкә авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов